**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2015 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон устанавливает меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан в целях повышения занятости и улучшения материального положения сельского населения, содействия развитию продовольственного рынка Республики Татарстан, а также определяет полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств.

Статья 2. **Общие положения**

1. Личное подсобное хозяйство ведется гражданином или гражданином и совместно проживающими с ним и (или) совместно осуществляющими с ним ведение личного подсобного хозяйства членами его семьи в целях удовлетворения личных потребностей на земельном участке, предоставленном и (или) приобретенном для ведения личного подсобного хозяйства.
2. Сельскохозяйственная продукция, произведенная и переработанная при ведении личного подсобного хозяйства, является собственностью граждан, ведущих личное подсобное хозяйство.
3. Реализация гражданами, ведущими личное подсобное хозяйство, сельскохозяйственной продукции, произведенной и переработанной при ведении личного подсобного хозяйства, не является предпринимательской деятельностью.
4. Для ведения личного подсобного хозяйства могут использоваться земельный участок в границах населенного пункта (приусадебный земельный участок) и земельный участок за пределами границ населенного пункта (полевой земельный участок).
5. Приусадебный земельный участок используется для производства сельскохозяйственной продукции, а также для возведения жилого дома, производственных, бытовых и иных зданий, строений, сооружений с соблюдением

градостроительных регламентов, строительных, экологических, санитарно-гигиенических, противопожарных и иных правил и нормативов.

6. Полевой земельный участок используется исключительно для производства сельскохозяйственной продукции без права возведения на нем зданий и строений.

Статья 3. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств**

К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств относятся:

1) законодательное регулирование вопросов оказания государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств;

2) утверждение в составе расходов бюджета Республики Татарстан объема средств, направляемых на государственную поддержку развития личных подсобных хозяйств;

3) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 4. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств**

К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств относятся:

1) утверждение государственных программ Республики Татарстан в области государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств;

2) определение органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного на реализацию мер государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств;

3) определение порядка осуществления мер государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств;

4) определение объема средств бюджета Республики Татарстан, направляемых на государственную поддержку развития личных подсобных хозяйств;

5) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 5. **Полномочия органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного на реализацию мер государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств**

К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного на реализацию мер государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств, относятся:

1) обеспечение функционирования системы финансовой поддержки развития

личных подсобных хозяйств за счет средств бюджета Республики Татарстан в формах, предусмотренных настоящим Законом;

2) совершенствование организационных механизмов, связанных с обеспечением средствами производства, заготовкой, переработкой и реализацией сельскохозяйственной продукции, производимой в личных подсобных хозяйствах;

3) осуществление иных полномочий в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Организационные меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств**

К организационным мерам государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств могут относиться:

1) содействие гражданам, ведущим личное подсобное хозяйство, в приобретении кормов; товарного и племенного поголовья коров, нетелей, козоматок, молодняка сельскохозяйственных животных, птиц (гусей, уток, индеек, цыплят-бройлеров); технологического оборудования для животноводства и птицеводства; семенного и посадочного материала, материалов и оборудования для ведения овощеводства защищенного грунта, средств защиты растений; информационно-консультационных услуг;

2) организация ветеринарного обслуживания сельскохозяйственных животных, борьба с болезнями сельскохозяйственных животных и птиц;

3) содействие гражданам, ведущим личное подсобное хозяйство, в создании сельскохозяйственных производственных кооперативов и сельскохозяйственных потребительских кооперативов;

4) организация работ по закупке сельскохозяйственной продукции, произведенной в личных подсобных хозяйствах;

5) содействие в привлечении кредитных ресурсов для развития личных подсобных хозяйств;

6) иные меры, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 7. **Финансовые меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств**

1. К финансовым мерам государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств могут относиться:

1) субсидии гражданам, ведущим личное подсобное хозяйство, на возмещение части процентной ставки по долгосрочным, среднесрочным и краткосрочным кредитам, взятым на цели, связанные с ведением личного подсобного хозяйства;

2) субсидии гражданам, ведущим личное подсобное хозяйство, на возмещение части затрат на:

а) строительство мини-ферм молочного направления;

б) приобретение товарного и племенного поголовья нетелей и первотелок;

в) приобретение товарного и племенного поголовья козоматок;

г) приобретение молодняка птиц (гусей, уток, индеек, цыплят-бройлеров);

д) услуги по искусственному осеменению коров;

е) приобретение кормов для содержания кобыл старше трех лет;

ж) проведение ветеринарных профилактических мероприятий по обслуживанию коров;

з) приобретение семенного и посадочного материала элитных сортов, материалов и оборудования для ведения овощеводства защищенного грунта, средств защиты растений;

3) иные меры, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. Конкретные финансовые меры государственной поддержки развития личных подсобных хозяйств определяются государственной программой Республики Татарстан в области государственной поддержки сельского хозяйства.

Статья 8. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань,Кремль
12 января 2016 года
№ 3-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон авыл халкының эш белән тәэмин ителешен арттыру һәм матди хәлен яхшырту, Татарстан Республикасының азык-төлек базарын үстерүгә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели.

2 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Шәхси ярдәмче хуҗалык граждан яисә граждан һәм аның белән бергә яшәүче һәм (яисә) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыручы гаилә әгъзалары тарафыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән һәм (яисә) сатып алынган җир кишәрлегендә шәхси ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында алып барыла.

2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясе шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның милке булып тора.

3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен реализацияләве эшкуарлык эшчәнлеге булып тормый.

4. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен торак пункт чикләрендәге җир кишәрлеге (өй янындагы җир кишәрлеге) һәм торак пункт чикләреннән читтәге җир кишәрлеге (кырдагы җир кишәрлеге) файдаланылырга мөмкин.

5. Өй янындагы җир кишәрлеге авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен, шулай ук, шәһәр төзелеше, төзелеш, экология, санитария-гигиена, янгынга

каршы һәм башка кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәгән килеш, торак йорт, житештерү, көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар, төзелмәләр торгызу өчен файдаланыла.

6. Кырдагы жир кишәрлеге анда биналар һәм корылмалар торгызу хокукыннан башка бары тик авыл хуҗалыгы продукциясе житештерү өчен генә файдаланыла.

3 статья. **Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен закон чыгарып җайга салу;

2) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменә юнәлдерелә торган акчалар күләмен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары составында раслау;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органын билгеләү;

3) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

4) Татарстан Республикасы бюджетының шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменә юнәлдерелә торган акчалар күләмен билгеләү;

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) әлеге Законда каралган рәвешләрдә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә финанс ярдәме системасы эшләвен тәэмин итү;

2) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, әзерләү, эшкәртү һәм реализацияләү чаралары белән тәэмин итүгә бәйле оештыру механизмнарын камилләштерү;

3) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру чаралары**

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең оештыру чараларына түбәндәгеләр керергә мөмкин:

1) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга терлек азыклары; товар өчен һәм нәселле сыерлар, таналар, кәҗәләр, авыл хуҗалыгы өчен яшь терлекләр, кош-корт (казлар, үрдәкләр, күркәләр, бройлер чебешләр) бәбкәләре; терлекчелек һәм кошчылык өчен технологик җайланмалар; сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен орлык һәм утырту материалы, материаллар һәм җайланмалар сатып алуда; мәгълүмати-консультатив хезмәт күрсәтүләрдә ярдәм итү;

2) авыл хуҗалыгы хайваннарына ветеринария хезмәте күрсәтүне оештыру, авыл хуҗалыгы хайваннары һәм кошлары авыруларына каршы көрәш;

3) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативлары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары төзүдә ярдәм итү;

4) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу эшләрен оештыру;

5) шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү өчен кредит ресурслары җәлеп итүдә ярдәм итү;

6) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка чаралар.

7 статья. **Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең финанс чаралары**

1. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең финанс чараларына түбәндәгеләр керергә мөмкин:

1) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга бәйле максатларда алынган озак сроклы, уртача һәм кыска сроклы кредитлар буенча процент ставкасы өлешен каплауга субсидияләр;

2) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга түбәндәгеләргә бирелгән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр:

а) сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүгә;

б) товар өчен һәм нәселле таналар һәм бер бозаулаган сыерлар сатып алуга;

в) товар өчен һәм нәселле кәҗәләр сатып алуга;

г) кош-корт (казлар, үрдәкләр, күркәләр, бройлер чебешләр) бәбкәләре сатып алуга;

д) сыерларны ясалма орлыкландыру буенча хезмәт күрсәтүләргә;

е) өч яшьтән зуррак бияләр асрау өчен азыклар сатып алуга;

ж) сыерлар асрауда хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә;

з) сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен элита сортлы орлык һәм утырту материалы, материаллар һәм җайланмалар сатып алуга;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка чаралар.

2. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәменең конкрет финанс чаралары авыл хуҗалыгына дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программасы белән билгеләнә.

8 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның, 12 гыйнвары
№ 3-ТРЗ